ГЛАВА СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление | Карар

“21 ” октябрь 2020 ел | № 3

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегенең Урта Кирмән торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Урта Кирмән авылы, Ленин урамы 16А йорт адресы буенча урнашкан Урта Кирмән авылы мәдәният йорты бинасында 2020 елның 13 ноябрендә сәгать 14.00 гә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Урта Кирмән торак пунктында үзарасалым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне распарга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлегенең Урта Кирмән торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Урта Кирмән авылында су алу колонкаларын төзекләндерү(павильон сатып алу һәм урнаштыру);

- Урта Кирмән авылы Муса Җәлил урамы буенча юлга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
-Урта Кирмән авылы урам утлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру(килешү буенча эш өчен түләү);
- Урта Кирмән авылында юлларны кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитетына Урта Кирмән авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә.

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы: Б.Ф.Хасанов